# Наратлы-Кичү авыл жирлеге башлыгының 2017 елның отчёты

Хәерле көн, хөрмәтле Айдар Фаслахович! Хөрмәтле җирлегебез депутатлары, авылдашлар, килгән кунаклар!

**1. Авыл җирлеге турында (җирлекнең көнкүреше ,башкарылган эшләр,халык саны, эш белән мәшгульлек, һ .б)**

Бүген без Наратлы-Кичү авыл җирлегенең 2017елның еллык отчеты-уңаеннан җыелдык.
Бүгенге отчет җыелышында катнашалар:
Минзәлә муниципаль район башлыгы Салахов Айдар Фаслахович. Һәм Минзәлә муниципаль районы оешма җитәкчеләре.
Бүгенге җыелышның көн тәртибе:
1.Авыл җирлегенең 2017 елга отчеты.
2.Участок полициясенең отчеты.
3.Мензелинские зори агрофирмасының ООО Калинин бүлекчәсенең җитәкчесе Акберов Ильдар Ахтямович чыгышы 4.Минзәлә муниципаль район башлыгы Салахов Айдар Фаслахович чыгышы.

Беренче көн тәртибе буенча сүзне уземә алам.
Наратлы-Кичү авыл җирлеге территориясендә 3 авыл урнашкан : Наратлы-Кичү, Шикәрле-Каен, Исангул авыллары . 2018 елның 1 январына алынган мәгълүматлар буенча: Ел башында җирлектә яшәүчеләр 441 кеше шуның эченнән татарлар 429 кеше, руслар 5 кеше , әрмән милләтеннән 7 кеше яши.

Шул исәптән җирлектә 165 пенсионер, 15 инвалид бар.
Эш яшендә 187 кеше, 35 бала яши.
Бюджет учреждениеләрендә барлыгы 12 кеше эшли.
Шуларнын 2 се Хужәмәт мәктәбенә йөреп эшли.
Наратлы-Кичү авыл җирлегендә эшләүче -59 кеше, 75 кеше -башка шәһәрләргә һәм авылларга йөреп эшли.
Безнең авыл җирлегендә кошчылык комплексы ачылды.
Ул җирлектәге халыкны эш белән тәмин итү өчен уңайлы. Анда безнен 10 кеше эшли. 1 магазин бар анда 3 кеше эшли. Авыл халкын кирәк-ярак белән тәэмин итеп тора.

**2. Авыл җирлегендә шәхси ярдәмче хуҗалыкларының, крестьян – фермер хуҗалыкларының эшчәнлеге.**
Җирлектә барлыгы 211 хуҗалык бар.
Безнең җирлектә халык мөгезле эре терлек асрау белән шөгелләнә .
Күпчелеге сыер асрап сөт һәм ит сата.
Шәхси хуҗалыкларда бугенге кондә
Барлыгы 702 мөгезле эре терлек. Шул исәптән 304 баш сыер асрала.

Безнең авыл җирлегендә бик тырыш кешеләр яши. Мал асрау өчен бөтен мөмкинлекләр бар.

Хөкүмәтебез сыер асраучы хуҗалыкларга сыер башына 3мең сум күләмендә субсидия бирде. Җирлектә 304 сыерга -912мең сум, 14 кәҗәгә- 14 мең сум, 17 баш атка -51 мең сум, каз асраучыларга 74000 сум күләмендә субсидия алынды. Мини фермалар програмалары буенча 2 хуҗалык 200 әр мең субсидия алдылар.

Авыл җирлегендә 2 КФХ бар.

Менә мәсәлән , Мингазов Рәзим КФХ -10 сыер, , КФХ Валиев Минненаил -30 сыер асрый.

КФХ булмаган шәхси хуҗалыкларда да сыерны бик күп асрыйлар. Мәсәлән, Мингазов Хайдар-15 сыер, Бикбаев Анвар - 20 сыер ,Сафиуллин Азат -8 баш сыер, Мингазов Халит-5баш сыер. Ахметшин Айдар-20 баш сыер,Курбанов Фарит-9 баш сыер, Абдуллин Рәис-5 баш, Мингазова Гөлфия-5баш сыер, Марданова Айгөлнен-5 баш сыер, Садыйков Расим -6 баш сыер, Бадрутдинов Фаил-8 баш сыер, Нуретдинов Рәшит -5 сыер.Исәнгол авылыннан Гиниятуллин Флус 9сыер, Шайхутдинов Наил -10 сыр, Гиниятуллин Фәнис -7сыер,Газизова Фатима -3сыер. Сыер булгач анын бозавы да була, куплэп угез,тана асрыйлар.

Олы мал тоту белән берлектә безнең авыл җирлегендә кош-корт асрау да киң җәелгән. Мәсәлән Мингазов Халит хуҗалыгында- 100 күркә, 100 каз;Мингазов Фарахетдин хуҗалыгында- 70 каз , 200 бройлер чебие, Набиуллина Энҗе -100 каз, 100 бройлер чебие; Хатыйпова Мәхтүмә -100 каз, 200 бройлер;Сафиуллина Диләрә- 100 каз, 70 үрдәк, 100 бройлер чебие, Мингазов Хайдар -200 каз, 150 бройлер чебие, Курбанов Фәрит - 100 баш бройлер чебие.

Калган хуҗалыкларда да 50-60 баштан да ким кош-корт асрамыйлар.

Авыл халкы жәй көнне үзенэ җитәрлек печәнне үз көче белән чабып өеп куйдылар.

Бадрутдинов Фаил, Мингазов Разим , Гиниятуллин Флус, Абдуллин Рәис, Курбанов Фәрит, Мингазов Хайдар, Мингазов Халит, Вәлиев Ирек үз тракторлары белән печән чабу,рулонга салу, алып кайту эшләрен башкаралар.

Мал асрау өчен һәр хуҗалык үзенә җитэрлек күләмдә фураж сатып алды, әзерләде.

Авыл җирлегендә бер хужалыкка 338000 сум керем туры килә. Барлыгы 138тонна ит, 158 тонна сөт җитештерелә һәм шуның 126 тоннасы сөт, 126т ит сатылды.

Халыкка үзеннән арткан продукцияне сату мөмкинлеге тудырылган. Бүген сөт җыю буенча проблема юк .Безнең авыл җирлегендә сөт җыю белән 2 кеше - Табанаков Сергей, Вәлиев Миңненаил шөгыльләнә, акчасын вакытында түләп баралар.

Районыбызда һәм Чаллы шәһәрендә ярминкәләр оештырыла.

Авыл халкы үзеннең җитештергән продукциясен шунда алып барып сата.

**3.Пай җирләре белән эшчәнлек.**

Пай җирләре тулысынча рәсмиләштерелеп бетерелгән. 9 хуҗалык 37 җир паен 292 га күләмендә рәсмиләштереп үзләре эшкәртеп печән, салам, фураж җитештерәләр.

Наратлы-Кичү авыл җирлеге буенча 2977,6 га пай җире рәсмиләштерелеп "Мензелинские зори" агрофирмасының Калинин бүлекчәсенә арендага бирелде.

Пай җирләре өчен август аенда халык 8 ц. исәбеннән фураж алды.

Пай жирләрен арендылау буенча тулысынча түләнеп бетерелде.

**4. Физик затлардан налог җыю күрсәткечләре.**

Җирлек буенча 468 мең сум налог җыю планда каралган иде. Үтәлеше - 418 мең сум үтәлгән.

Мөлкәт өчен налог план буенча- 45мең , чынлыкта 46 мең жыелды. Бу 101% тәшкил итэ.

Җир өчен налог план буенча 275 мең, чынлыкта 275 мең жыелды. Бу 100% тәшкил итэ.

**5.Инфраструктура (җирлектәге юллар торышы , яктылык белән тәэмин ителү, халыкка комуналь хезмәт күрсәтү).**

Авыл җирлегендә юллар төзек, кышкы чорда кардан чистартылып торыла.
Су белән тәэмин ителү х
һәр кешенең үз өендә кое бар. Шикәрле-Каен авылында су башнясы бар. Аны документлаштыру 2018 елның узаара салым акчасына планлаштырыла.

**6.Халыктан үзара салым җыю күрсәткәчләре һәм нәтиҗәләре. (2016-2017елга факт һәм 2018 елга планнар).**

Наратлы-Кичү авыл җирлеге буенча 2016 ел өчен узара салым акчасы 74411 сум күләмендә җыелды, 351 мең күләмендә республикадан акча алынды. Шул акчаның 348 меңе тотылды. Наратлы-Кичү авыл урамнарына яткырткыч утлар куелды. Шикәрле- Каен авылына пожарный гидрант урнаштырылды.

2017 елда 71400 сум акча җыелды, 354мең күләмдә республикадан акча алынды. Шул акчаның 124500 тотылды. Узарасалым акчасына Исангол авыл урамына яктырткыч утлар куелды. Шикәрле-Каен авылының су башнясының түбәсе ябылачак. Калган акчага Наратлы-Кичү авылының зиаратын зурайтуга тотылачак.

**7.Авыл җирлеге депутатларының һәм спонсорларының эшчәнлеге.**

Хәзерге көндә Наратлы-Кичү авыл җирле Советында 7 депутат план нигезендә эш алып баралар. Ай саен сессияләр үткәрелә. Төрле сораулар карала. Милли бәйрәмнәр һәм башка мәдәни чаралар уткәргәндә иганәчелек курсәтәләр . Мәсәлән 9 май җину бәйрәме, Сабан Туй, өлкәннәр көне. Яңа ел үткәрүдә булышалар. Вәлиев И.М, Курбанов Ф.Р, Мингазова Г.Ш.

**8.Авыл җирлегендә клублар эшчәнлеге (үткәрелгән чаралар һәм, милли бәйрәмнәр).**

Мәдәният йортында төрле чаралар үткәрелә. Аеруча истә калганнары:

- Иске яңа ел үткәрү, 23 нче февраль ,8 нче март халык- ара хатын-кызлар көне,

-9 май бәйрәме, Сабан туй,

- өлкәннәр көне зурлап үткәрелде.

-яңа ел бәйрәме бик күңелле узды. Шулай ук сирәгрәк булса да артистлар да килеп тора. Узебезнең авылдан чыккан жырчы Резеда Шәрафиева һәм Алсу Әбелханова бик күңелле концерт күрсәттеләр.

**9.Белем**

Китапханәдә һәр юбилей һәм истәлекле даталар билгеләп үтелә. Китап күргәзмәләре, кичәләр оештырыла. Китап яшьлекне туендыра, ә картлыкның күңелен күтәрә,ди.

Шуңа күрә балаларыбыз китапханәдән тулысынча файдаланасын, ә картларыбыз үзләренең күңелләренә хуш килгән китапларны укып күнелләрен күтәрсеннәр.

2017 елда планлаштырылган эшләр нигездә үтәлде дип әйтәсем килә.

**10. 2018 нчы елга бурычлар һәм планнар.**

- Халыктан җыелган салым акчасына Шикәрле-Каен авыл су башнясын лицензияләштерүгә һәм койма белән әйләндереп алуга тотылачак. Наратлы-Кичү, Исангол авыллары урамнарына яктырткыч утлар куюны дәвам иттереләчәк .
- Наратлы-Кичү авыл урамнарын яхшырту.
- Шәхси хуҗалыкларда мал һәм кош-корт санын арттыру.
- Программаларда катнашкан гражданнарга булышу.

*Хөрмәтле иптәшләр! 2017 елда сезнең белән бергәләп эшләгән эшләребезнең төп моментлары шушылар иде.*
*2018 елда алда торган бурычларны хәл итүдә барыбыз да бергәләп эшләрбез дип ышанып калам.*

*Сүземне йомгаклап шуны әйтәсе килә,*
*киләчәктә дә бергә- бергә авылларыбызны күтәрү, үстерү өстендә нәтиҗәле эш алып барырга, һәм барыбызга да исән-сау, сәламәт яшәргә язсын.*